**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «25» маеннан № 134

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм җитәкче вазыйфасына кандидатларга аттестация үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 17 ноябрендәге 336 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары номенклатурасын раслау турында» 2022 елның 21 февралендәге 225 номерлы карары нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 ноябрендәге 336 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм җитәкче вазыйфасына кандидатларга аттестация үткәрү турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Әлеге Нигезләмәне куллану максатларында мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре, мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасын раслау турында» 2022 елның 21 февралендәге 225 номерлы карары нигезендә «Җитәкчеләр» категориясенә кертелгән вазыйфалар керә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов